КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 февраль г.Казань № 78

М.Җәлил исемендәге Республика
премиясен бирү турында

М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты утырышы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 - 2021 еллар конкурсы йомгаклары буенча М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирергә:

Закиров Илнур Ильяс улына һәм Закирова Динә Ильяс кызына, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистларына татар телен һәм мәдәниятен саклауга, үстерүгә, популярлаштыруга зур өлеш керткән өчен;

Захаров Иван Васильевичка, эшмәкәргә - «CLEAPL» инновацион проектын эшләү, экологик яктан куркынычсыз технологияләр булдыру өчен;

Камалов Ильяс Фәйзрахман улына,Татарстан Республикасы Дәүләт кыллы квартеты артистына Татарстан Республикасы музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен;

Абдуллин Роман Фарист улына, рәссам-монументалистка, Россия Федерациясе Рәссамнар берлеге әгъзасына, Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге әгъзасына сынлы сәнгать өлкәсендәге күренекле казанышлары өчен;

Ибраһимов Булат Хәким улына, шагыйрьгә, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасына, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге әгъзасына яңа буын татар шигъриятендә зур әдәби-эстетик кыйммәткә ирешкән өчен.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин